
# Дулкыннарга каршы борам Тормышымның көймәсен...



Галиәхмәт ШАҺИ

*__Галиәхмәт Шаһиәхмәт улы Шаһиәхмәтов__ 1949 елның 24 августында Татарстанның Арча районы Шура авылында туа. Шагыйрь, күпсанлы җырлар һәм дистәгә якын шигъри җыентык авторы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Яр Чаллы шәһәрендә яши. Каләмдәшебез бу айда 75 яшьлек гомер бәйрәмен каршылый. Аны редакция исеменнән ихлас тәбриклибез. Нык сәламәтлек, сүнмәс иҗат дәрте, бәрәкәтле озын гомер телибез.*

## Моң чишмәсе

Моң чишмәсе саекмаган әле,
Безнең гомерләргә җитәрлек.
Юкка гынамыни шигъриятне
Байрак итеп өскә күтәрдек.

Сөю уты сүрелмәгән әле,
Элеккедән күпкә көчлерәк.
Юкка гынамыни шагыйрьләрнең
Күңелләре, диләр, хислерәк.

Илдә кайгы кимемәгән әле,
Киметергә тагын без кирәк.
Кыен вакытларны үткәрергә
Көч бирерлек җылы сүз кирәк...

## Сәяхәт

Дөнья буйлап сәяхәттә йөрим,
Каурый каләм тотып кулыма.
Яңа фикер, гади сүзләр эзлим,
Тезәр өчен шигырь юлына.

Үземнән соң шигъри юллар калса,
Озын булыр минем гомерем.
Күңелләргә салып китим әле
Йөрәгемнең утлы күмерен.

## Сагынам

Таш калада җилгә ялынам,
Алып кил, дип, чәчәк исләрен.
Мин аларны шундый сагынам,
Исләреннән таныйм төсләрен.

Яңгыр болытына ялынам,
Сафландырып үт, дип, һаваны.
Чишмә челтерәвен сагынам,
Анда безнең яшьлек дәвамы.

Һавадагы кошка ялынам,
Әйтче, кайда сөйгән ярым, дип.
Мин аны бит шундый сагынам,
Кай тарафка эзләп барыйм, дип.

Янган йөрәгемә ялынам:
Янма, әйләнерсең күмергә.
Авылымны шундый сагынам,
Ничек кенә кайтып килергә?..

## Ак җилкәннәр

Идел өстендәге ак җилкәннәр
Бүген бигрәк ишле күренә.
Ия кирәк чагы күңелемнең
Әйтелмичә калган серенә.

Идел өстендәге ак җилкәннәр
Әйләнәләр Казан каласын.
Вакытында әйтелмәгән сүз дә
Үкендерә адәм баласын.

Идел өстендәге ак җилкәннәр –
Мавыктыргыч, гүзәл тамаша.
Алып килер идем сөеклемне,
Басып торсын иде янәшә.

Идел өстендәге ак җилкәннәр
Йөрәк аша үтә тезелеп.
Ходай сабырлыктан аермасын,
Үзәкләрем китә өзелеп.

## Туган илләрдә генә

Яшь вакытта безнең күзләр
Аллар-гөлләрдә генә.
Алы да бар, гөле дә бар
Туган илләрдә генә.

Ай чәчәге – төнбоеклар
Безнең күлләрдә генә.
Иң бәхетле көннәр үткән
Туган илләрдә генә.

Шомырт төсле кара чәчләр
Тузгый җилләрдә генә.
Кара чәчле гүзәл кызлар
Туган илләрдә генә.

Ин матур җыр, иң моңлы җыр
Туган телләрдә генә.
Туган телдә сөйләшәбез
Туган илләрдә генә.

## Янар йөрәк янар

Килер бәхет – килер.
Аның килгән көнен
Йөрәк үзе белер.

Янар йөрәк – янар.
Ничә ярасы бар –
Кемнәр аны санар?

Үтәр көннәр – үтәр.
Гомер үткән бит дип,
Бер көн исең китәр.

Исәр җилләр – исәр.
Онытылган җырлар
Исләреңә төшәр.

## Ак болытка карап

Ак болытлар, гүя ак тулпарлар,
Ак ялларын җилләр тарасын.
Ак тулпарга йөгән кидерергә
Ничек кенә табыйм чарасын?

Атланып шул ак ат билләренә
Әйләнәсе иде дөньясын.
Ак болытка карап, уйга калам...
Кайда икән минем ун яшем?

Сагынырга гына калды инде
Бала чакны, яшьлек елларын.
Чәчне тарап, җилләр хәтерләтә
Сөеклемнең назлы кулларын.

Күңел бит ул унсигездә чакта,
Яшьлек үтмәс, диеп уйлады.
Яратам, дип әйтүчеләр бетте,
Йөрәк яраттырып туймады.

## Урманнарда йөрдем

Урманнарда йөрдем, уф димәдем,
Ут кабар дип урман эчләренә.
Яшьлегеңнең сандугачы булып
Төшсәм иде синең исләреңә.

Урманнарда йөрдем, хәтер буйлап,
Сагынылган таныш сукмакларым.
Буйга үскән каеннарны танып,
Билләреннән кысып кочакладым.

Урманнарда йөрдем, рәхәтләнеп
Аңкып торган чәчәк исләренә.
Бәлки, соңгы тапкыр, хозурланып
Карап үттем җәйнең төсләренә.

## Таш чәчәк

Мәйдан түрендәге таш чәчәкне
Яңгыр юа, җилләр киптерә.
Бәйрәмнәрдә халык мәйданнарга
Тере чәчәк җыеп китерә.

Күпме чәчәк исән калыр иде,
Сугышларсыз гына яшәсәк, –
Шуны исегездән чыгармагыз,
Дип кисәтә безне таш чәчәк.

Ярларыннан ташып чыккан мәле
Күңелләрнең сагыш күлләре.
Майлар килгән саен, ташка ятып
Саргаялар хәтер гөлләре.

Яңгыр юа, җилләр шомарталар
Таш чәчәкнең таҗын, чукларын.
Кайсы ана горурлана ала,
Үстердем, дип, сугыш чукмарын?

Таштан чәчәк иҗат итүченең
Әнкәсенә башым иям мин.
Таш калада, мәйдан уртасында
Ялкынланып янам, көям мин.

Бәйләм-бәйләм хәтер чәчәкләре
Күзләремә карап яталар.
Гөлләр, гөлләр! Туган җиребездә
Яшәргә дип чәчәк аталар.
Ә үзләре
Мәйданнарда шиңеп яталар.

## Дөнья

Ишек бикле, һәм мин тышкы якта,
Ачкычым юк ачып керергә.
Дөнья якты. Миңа язган икән
Караңгыда капшап йөрергә.

Пәрдә ябык, һәм мин тышкы якта,
Эчтән шәүлә генә күренә.
Минем җаным, төнге күбәләктәй,
Якты тәрәзәгә үрелә.

Бикле ишек, ябык тәрәзәгә
Бәреләм дә, сына канатым.
Йөрәгемнең мәңге төзәлмәслек
Яраларын кабат канаттым.

Төне буе шомлы тавыш белән
Шаулады да урман шаулады.
Туктамады дөнья минем янда –
Алга карап, атын каулады.

## Балачакка кайтам

Балачакка кайтам, балачакта
Атлы чана көтә, ак юллар...
Шул юллардан, мине каршыларга
Йөгереп килер кебек ак еллар.

Атлы чана, шикәр кебек ак юл –
Минем хәтер шуннан башлана.
Шуннан өзелмичә дәвам итә...
Һава салкын, яка бәсләнә.

Әнкәй миңа мамык шәлен урый,
Әткәй кызулата «Кашка»ны.
Колагымнан китмәс әтиемнең:
«На, малкай», – дип атка дәшкәне.

Балачакка кайтам, ак юлларда
Хәтер йомгагымны сүтәрмен.
Сары каеш дилбегәсен тотып,
Ак атларда кабат үтәрмен.

Әнкәй миңа мамык шәлен урар,
Әткәй салып бирер чикмәнен.
Балачакка кайтам. Әткәй-әнкәй,
Сезне бүтән ташлап китмәмен.

## Гомер – бүләк

Нигә тудык?
Дөнья кудык...
Аңламадык, гомер – бүләк.
Китә кеше
Бүләк өчен
Гөнаһлары белән түләп.

Кемнәр хаким,
Кемнәр ятим...
Ятимнәрне искә алыйк.
Халык мактар,
Дин дә яклар,
Игелекләр эшләп калыйк.

Килә кышлар,
Әйдә, дуслар,
Чәчәк исен иснәп калыйк.
Гомер кыска,
Бу тормышта
Изгелекләр эшләп калыйк.

## Бәхетемә тәхет

Җимерелгән чакта дөньям,
Өзелгәндә үзәгем.
Елый-елый бәхетемнең
Кирпечләрен тезәмен.

Димен: минем йөрәгемә
Җил-яңгырлар тимәсен.
Дулкыннарга каршы борам
Тормышымның көймәсен.

Өр-яңадан төзеп куям
Бәхетемә тәхетне.
Миңа насыйп бәхет белән
Ятлар булмас бәхетле.